**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче**
**Мрәс авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

14 ноябрь 2023 ел № 03

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 14 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Иске Абдул авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Мерәс авылында С.Сәйдәш урамында урам спорт мәйданчыгын сатып алу;
- Мерәс авылында электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру буенча эшләр башкару;
- Мрәс авылында балалар мәйданчыгы урнаштыру (балалар өчен уен элементларын сатып алу, урнаштыру)

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 156 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 83 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 83 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм

көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Иске Абдул авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Мерәс авылында С.Сәйдәш урамында урам спорт мәйданчыгын сатып алу;
- Мерәс авылында электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру.

3. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мрәс авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мрәс авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина